ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“27” октябрь 2023 ел № 2

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең Шилнәбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Шилнәбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2023 елның 10 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта Шилнәбаш авылында Нагорный, Төньяк, яңа, Заречная урамнары буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2023 елның 10 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Шилнәбаш авылында мәктәп, Октябрьнең 60 еллыгы, буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2023 елның 10 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта Шилнәбаш авылында Мордвинов, Яшьләр, Кыр,Октябрьнең 60 еллыгы, белгечләр тыкрыгы буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Шилнәбаш авыл җирлегенең Шилнәбаш авылы территориясендә 2024 елда балигъ булган, Шилнәбаш авыл җирлегенең Шилнәбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- гомуми кулланылыштагы урыннарны төзекләндерү (парковка урыннарын, каты көнкүреш калдыклары мәйданчыкларын, урналар һәм эскәмияләр сатып алу);
- вак таш белән юллар сатып алу һәм салу, юлларга чокырларны ямау;
- Шилнәбаш авылындагы суэтем башняларын сатып алу һәм урнаштыру;

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

5. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Шилнәбаш авылы, Октябрьнең 60 еллыгы ур., 2 йорт.

Шилнәбаш авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.

6. Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

8. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

9. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Шилнәбаш авыл
җирлеге Башлыгы | О.А. Гончарова